ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

«03» апрель 2024 ел Иске Абдул авылы № 06

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче Мерәс авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 03 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 14 ноябрендәге 03 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Мерәс авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Мерәс авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 ноябрендәге 10/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче Мерәс авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 03 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 14 ноябрендәге 03 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Мерәс авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апрель 16.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче Иске Абдул авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 01 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Мерәс авылында электр материаллары сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру)ремонтлау; »

«-торак пункт территориясен төзекләндерү (Мерәс авылының урам спорт мәйданчыгын сатып алу)».

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 15 ноябрендәге 01 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Иске Абдул авылында гражданнар җыены карарына:

«-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Мерәс авылында электр материаллары сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру)ремонтлау; »

«-торак пункт территориясен төзекләндерү (Мерәс авылының урам спорт мәйданчыгын сатып алу)».

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Иске Абдул авыл җирлеге, Мерәс авылы, С.Сәйдәш ур., 24 йорт (Мерәс мәдәният йорты бинасы).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина